РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 55 2018 елның 19 декабре

**2019-2021 елларга Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру фараз планын (программасын) раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 15 сентябрендәге 22нче номерлы карары белән расланган «Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль милегенә ия булу, файдалану һәм эш итү тәртибе турында» Нигезләмәсе нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019-2021 елларга Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) расларга (теркәлгән).
2. Түбән Кама шәһәре Башкарма комитетына 2019-2021 елларга Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә тормышка ашыруны тәэмин итүне йөкләргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеше буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2018 елның 19 декабрендәге
55нче номерлы карарына
кушымта

**2019-2021 елларга Түбән Кама муниципаль районы**
**Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең**
**муниципаль милкен хосусыйлаштыру**
**Фараз планы (программасы)**

## 1нче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. 2019-2021 елларга Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планы (программасы) (алга таба – фараз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 15 сентябрендәге 22нче номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре муниципаль милегенә ия булу, файдалану һәм эш итү тәртибе турында Нигезләмәсе нигезендә эшләнгән.

2.. Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең 2019-2021 елларда муниципаль милекне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыруга, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет дефицитын каплау чыганакларын формалаштыруга юнәлдерелгән.

3. Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль милегенә ия булу, файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукцион яки бәйгедә һәм законда каралган башка ысуллар белән сату итү юлы белән үткәрү күздә тотыла.

## 2нче бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

1. 2019-2021 елларда Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендә булган муниципаль милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

2. Хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль күчемсез милек исемлеге:

| т/с | Исеме | Урнашу урыны | Гомуми мәйданы, кв.м, җир кишәрлеге мәйданы, кв.м | Хосусыйлаштыруның ниятләнгән вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Җир кишәрлеге белән административ-көнкүреш | Түбән Кама шәһәре, Менделеев урамы, | 334,7 кв.м 373+31 кв.м | 2019 ел |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бинасы | 46А йорты | | |

3. Күчмә милек Түбән Кама шәһәре Башкарма комитетының аерым карарлары нигезендә хосусыйлаштырылырга мөмкин.

4. 2019-2021 елларда муниципаль милектә булган акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

**3нче бүлек. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү**

1. Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең милкен хосусыйлаштыру турында мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм тагы да киңрәк реклама белән тәэмин итү максатыннан, Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты Фараз планын үтәү барышында рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш башка гаммәви мәгълүмат чаралары хезмәтләреннән дә файдаланырга хокуклы.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина